**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы № 110 17 сентябрь 2018 ел.

Уразай авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Уразай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Уразай авылы башкарма комитетының 03 сентябрь 2018 елда чыккан 13 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Уразай авыл җирлеге Советының 03 сентябрь 2018 елда чыккан 109 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Уразай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Уразай авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 18 ноябрь 2018 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда карaласы мәсьәлә:
   “Сез, Уразай авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2019 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, I инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) авыл халкынын ялын оештыру:
1.1 бэйрэмнэр оештыру һәм үткәрү(Җиңү бәйрәме,сабантуй, балаларны яклау көне,халыкара өлкәннәр көне),
1.2 сабантуй мәйданында сәхнә һәм трибуналарны төзү;

2) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру::

2.1 Уразай авылында урамнарны яктыртуны карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электртоварлар сатып алу һәм алмаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү,

2.2 агач кистерү,

2.3; Уразай авыл юлларын кардан чистарту;

3) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

3.1 янгын ранчыларын сатып алырга,

3.2 огнетушительлэр сатып алу;

4) җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны оештыру очен шартлар тудыру , авыл жирлегендэ рәсми физкультура - сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру:

4.1 спорт залга ремонт,

4.2 спорт инвентаре сатып алу,

4.3 спорт залнын коммуналь хезмэтлэре очен тулэу.

ӘЙЕ ЮК

1. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
2. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис: А.М.Шәрифуллина